**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ СРЕДНЕДЕВЯТОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

422614 с.Среднее Девятово
ул. Сергеева, д.9
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА ДЕВЯТОВО АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422614 а.Урта Девятово
Сергеев урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

# КАРАР

**№15** **2019 елның 24 апреленнән**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына караган вазифалардан тыш) хезмәтенә түләү шартлары һәм оештыру турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге Советы карар бирә:

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына караган вазифалардан тыш) хезмәтенә түләү шартлары һәм оештыру турындагы кушып бирелүче Кагыйдәне расларга.

1. Хезмәткәрләрнең әлеге карарга ярашлы төстә билгеләнгән хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләрнең вазифаи бурычлары күләме сакланганда һәм алар тарафыннан шул ук квалификация эшләре башкарылганда, 2019 елның 31 мартына түләнгән хезмәт хакы күләменнән кимрәк була алмый.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге Советының 2018 елның23 апреленнән №9 “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм сеткага кермәгән бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында”гы карарын көчен югалткан дип табарга.
3. Бу карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 апреленә булган хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына караган вазифалардан тыш) вазифалары исемен әлеге карарга ярашлы төстә бирүне тәэмин итәргә.
5. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне муниципаль районның Урта Девятово авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - ТР Лаеш муниципаль районы**
**Урта Девятово авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **О.Н.Чумарова**